| | |
|---|---|
| **СОВЕТ СТАРОТЯБЕРДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ТӘРБИТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26 январь 2022ел Иске Тәрбит ав. № 4

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Советының 10.08.2017ел. 12 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 апрелендәге 116-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәне раслау турында» 10.08.2017ел. 12 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында» нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 сатьяның 1 өлешендәге 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) Россия Федерациясе гражданлыгы йә Россия Федерациясе аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы туктатылу, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) йә чит ил гражданы Россия Федерациясе территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган чит ил гражданы яисә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокукы булган чит ил гражданы булу;».

2. Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://styaberdin-kaybici.tatarstan.ru/ веб - адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль районы
Иске Тәрбит авыл җирлеге Башлыгы В.Г.Тимофеев